**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чула торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены карары**

**14 .12. 2023** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пунктында гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пункты территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Чулла торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә акча кертергә.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

-Чулла торак пунктында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча зиратка поселок эчендәге юлны ремонтлау: вак таш, ком сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, эшләр, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

**Җитәкче** **Н.Г. Салихов**